ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
20.06.2024

**К А Р А Р**
№ 561

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» 2019 елның 29 маендагы 773 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә һәм шәһәр һәм авыл җирлекләре бухгалтерларына хезмәт хакы түләү турында» 2024 елның 18 апрелендәге 03-12/2677 номерлы хаты нигезендә һәм муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның «Биектау муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» 2019 елның 29 маендагы 773 номерлы карары (5.10.2020 елның №769, 8.12.2022 елның №1138 белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУнең Мәдәният бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Мәгариф бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ үзәкләштерелгән

бухгалтерияләре җитәкчеләре һәм белгечләренең айлык вазыйфа окладлары күләмен 2024 елның 1 июленнән арттырырга.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУнең Мәдәният бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУнең Мәгариф бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» Нигезләмәсенең 3 пунктындагы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләре һәм белгечләре вазыйфаи окладлары» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Җитәкче һәм белгеч вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органы) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 35 800 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 34 200 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 34 200 |
| Бүлек башлыгы | 28 500 | 28 500 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 24 800 | 24 800 |
| Бухгалтер | 23 300 | 23 300 |

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль

районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

5. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисенә йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин